**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСАНДРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(84378) -3-54-22
факс: 8-(84378) -3-54-22

422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(4378) -3-54-22
факс: 8-(4378) -3-54-22

---

**2024елның «07» марты** **3 номер**

# КАРАР

**Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Александр авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:24:080603:554 кадастр номерлы җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияне чикләү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә мохитне саклау, территорияләрне планлаштыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясының 1 пункты, 30, 31, 32 статьялары нигезендә инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:**:**

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Александр авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:080603:554, мәйданы 509259+/- 16244кв.м. булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияне чикләү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Халык тыңлауларын үткәрү датасы һәм вакыты 2024 елның 17 апреле 15.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - Александр авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, ТР, Лаеш районы, Александр авыл җирлеге, и. 25 октябрь, Үзәк урам, 7А йорт;

2.3. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2024 елның 16 апреленә кадәр; язма рәвештә, эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: ТР, Лаеш районы, Александр авыл җирлеге, и. 25 октябрь, Үзәк урамы, 7А йорт, гражданнар өчен мәҗбүри күрсәтмә белән: фамилия, исем, ата исеме, яшәү урынын теркәү адресы, эш урыны һәм биләгән вазифасы, контакт телефоннары; гражданнар төркеме өчен фамилияләр, исемнәр, ата исемнәре, нинди дә булса иҗтимагый оешмаларга яки берләшмәләргә караганлык (әгәр булса), яшәү урынын теркәү адреслары, контакт телефоннары, юридик затлар өчен оешма бланкында, җитәкченең фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтеп.

2.4. Ачык тыңлауларга чыгарылган объект территориясен чикләү проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынучы затлар тарафыннан ТР, Лаеш районы, и. 25 октябрь, Үзәк урам, 7А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге башкарма комитетына 8 сәгать 00 минуттан 12 сәгать 00 минутка кадәр, 13 сәгать 00 минуттан 16 сәгать 00 минутка кадәр язма рәвештә тапшырылырга мөмкин 2024 елның 16 апреленә кадәр (шул көнне кертеп).

3. Александр авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Лаеш районы Александр авыл җирлегенең 16:24:080603 кадастр кварталында дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне яңадан бүлү юлы белән барлыкка килә торган торак пунктлар җирләре категориясеннән, гомуми мәйданы 509259+/-16244кв.м. булган җир кишәрлеген планлаштыру һәм чикләү проекты буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү буенча эшче комиссия төзергә.

4. Эшче комиссиягә:

4.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәр итүне әзерләргә;

4.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 7 эш көненнән дә соңга калмыйча «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә әлеге карарның 4.1 пунктында күрсәтелгән кисәтүне бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) ;

4.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән дата һәм вакыт буенча ачык тыңлаулар үткәрергә;

4.4. Җәмәгать тыңлаулары тәмамланганнан соң 5 көн эчендә ахыргы карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен һәм җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмәне җибәрергә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Александр**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **А.А.Гогонов**